КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 июль г.Казань № 600

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 ел, 13 август, 675 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 июль, 597 нче, 2023 ел, 7 июнь, 692 нче, 2023 ел, 7 июль, 793 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә башкарылган эшләр һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертиза, тикшерүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрү.»;

түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13. Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә үлчәү эшләре башкару.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин